**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны айлык акчалата бүләкләү күләмен арттыру

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2025 елның 1 гыйнварыннан «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында» 2006 елның 27 мартындагы ПУ-122 номерлы (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 29 декабрендәге ПУ-597 номерлы, 2007 елның 12 октябрендәге ПУ-538 номерлы, 2008 елның 28 апрелендәге ПУ-168 номерлы, 2010 елның 6 маендагы ПУ-295 номерлы, 2010 елның 15 июлендәге ПУ-461 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-585 номерлы, 2011 елның 21 апрелендәге ПУ-230 номерлы, 2011 елның 6 августындагы ПУ-480 номерлы, 2013 елның 2 августындагы ПУ-705 номерлы, 2013 елның 22 октябрендәге ПУ-1031 номерлы, 2014 елның 10 апрелендәге ПУ-348 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2018 елның 7 апрелендәге ПУ-295 номерлы, 2020 елның 11 мартындагы ПУ-164 номерлы, 2020 елның 15 августындагы ПУ-497 номерлы, 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-663 номерлы, 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 13 июлендәге 490 номерлы һәм 2024 елның 10 маендагы 334 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны айлык акчалата бүләкләү күләмен арттыру һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында» Указына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 15 августындагы ПУ-497 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны айлык акчалата бүләкләү күләмен арттыру турында» 2022 елның 19 августындагы ПУ-574 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны айлык акчалата бүләкләү күләмен арттыру һәм Татарстан

Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында» Указына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 23 сентябрендәге ПУ-663 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны айлык акчалата бүләкләү күләмен арттыру һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны акчалата бүләкләү турында» Указына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 10 маендагы 334 номерлы Указы нигезендә билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны айлык акчалата бүләкләү күләмен арттырырга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны айлык акчалата бүләкләү күләмен исәпләгәндә, әлеге Указның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы министрын айлык акчалата бүләкләү күләмен 1,05 тапкырга индексацияләргә һәм ул 48 871 сум тәшкил итәчәк.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыру буенча башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 03 октябрь
№ 775